ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендә:

а) $9^3$ пунктта “текст рәвешендәге һәм график тасвирламасын” сүзләрен “график тасвирламасын” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^5$ һәм $9^6$ пунктлар өстәргә:

“$9^5$) капиталь төзелеш объектының проект документациясе бүлеген карау һәм аның тарихи җирлекнең саклау предметына һәм Федераль законның 60 статьясындагы 9 пункты нигезендә шәһәр төзелеше регламенты белән тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектурасына карата таләпләргә туры килүе яисә туры килмәве турында бәяләмә җибәрү;

$9^6$) индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы күренеше тасвирламасын карау һәм аның тарихи җирлекнең саклау предметына һәм Федераль законның 60 статьясындагы 13 пункты нигезендә шәһәр төзелеше регламенты белән федераль яисә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектурасына карата таләпләргә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрү;”;

2) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14 статья. **Мәдәни мирас объектларын саклау зоналары**

1. Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына кагылышлы мәдәни мирас объектларын саклау зоналарын, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасын (Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәткә ия мәдәни мирас объектларын һәм Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларын саклау зоналарыннан тыш) билгеләү, үзгәртү турында карарлар, әлеге зоналар территорияләре чикләрендәге шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр, мәдәни мирас объектларын саклау зоналары проектларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге вәкаләтле органы, территориясендә мәдәни мирас объекты урнашкан муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, ә федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына йә мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасы проектына кагылышлы булганда, мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә һәм раслана. Мәдәни мирас объектларын саклауның күрсәтелгән зоналарының гамәлдә булуын туктату турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

Мәдәни мирас объектын саклау зоналары, мәдәни мирас объекты Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылган очракта, мондый зоналарның гамәлдә булуын туктату турындагы карар кабул ителмичә генә гамәлдә булудан туктыйлар.

2. Мәдәни мирас объектын саклау зоналары Федераль законның $34^{1}$ статьясы нигезендә саклау зонасы итеп билгеләнгән мәдәни мирас объекты Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән көннән алып иң күбе ике еллык срокта билгеләнергә тиеш.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 94-ТРЗ